## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 12 ноябреннән** **№ 1**

2025 елның 20 марты № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45, 69 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Бикбау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Бикбау торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, МХО зонасында хезмәт итүче гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Бикбау торак пункты Садовая урамындагы юлны ремонтлау (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бикбау торак пункты юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәтләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге башлыгы ____________________ Л. Н. Мәрдәмшина